КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 сентябрь г.Казань № 667

Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамалар каталогы турында

Татарстан Республикасындагы географик объектлар атамаларының татар телендә бертөрле һәм тотрыклы кулланылышын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамалар каталогы турындагы нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесен «Географик объектлар атамалары турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3 өлешендә каралган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы учреждение итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 6 сентябрь, 667 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасындагы географик объектларның
татар телендә атамалар каталогы турында
нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасындагы географик объектлар атамаларының татар телендә бертөрле һәм тотрыклы кулланылышын тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының, башка оешмаларның һәм гражданнарның Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамалары турындагы мәгълүматка ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында, «Географик объектлар атамалары турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон, «Геодезия, картография һәм пространство мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге ФЗ-431 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды турында» 2018 елның 14 декабрендәге 1133 номерлы карары нигезендә эшләнде.

2. Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамалар каталогында (алга таба – Каталог) әлеге Нигезләмәнең кушымтасында бирелгән форма буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Географик объектлар атамаларын теркәү һәм исәпкә алу, географик объектлар атамалары сүзлекләрен һәм белешмәлекләрен бастырып чыгару, шулай ук Географик атамаларның дәүләт каталогын төзү һәм аны алып бару эшләрен башкару тәртибен раслау турында» 2022 елның 22 июнендәге П/0241 номерлы боерыгы нигезендә теркәлгән һәм исәпкә алынган географик объектлар атамалары турында мәгълүмат бирелә.

3. Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамаларын билгеләү «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Каталог операторы) тарафыннан башкарыла.

4. Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамаларын билгеләү чыганаклары:

географик объектлар атамалары турында законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары;

гомуми географик һәм топографик карталар;

Татарстан Республикасындагы административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестры;

тарих һәм архив документлары;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан алынган, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе белән килештерелгән мәгълүмат;

географик объектларның атамаларын раслый торган башка документлар.

5. Каталог операторы түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамаларын билгеләүне;

Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамаларына үзгәреш кертүне;

Каталогтагы белешмәләрне бирүне;

Каталогта җибәрелгән техник хаталарны бетерүне.

6. Каталогтагы белешмәләр Татарстан Республикасының мәгълүмат ресурсы булып тора.

7. Каталог белешмәләре һәркем файдалана алырлык гомуми мәгълүмат булып тора һәм Каталог операторының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Татарстан Республикасындагы
географик объектларның татар
телендә атамалар каталогы
турындагы нигезләмәгә
кушымта

Форма

## Татарстан Республикасындагы географик объектларның татар телендә атамалар каталогы

| Т/с | Географик атамалар буенча дәүләт каталогының теркәү номеры | Географик объектның рус телендәге атамасы | Географик объектның татар телендәге атамасы | Географик объектның рус телендәге төре | Географик объектның татар телендәге төре | Географик объектның торыш билгесе | Муниципаль берәмлекнең татар телендәге исеме | Географик объектның координатлары, ГСК-2011 | | Татарстан Республика сындагы географик объектларн ың татар телендәге атамаларын билгеләү чыганагы һәм датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | киңлеге | озын-лыгы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| | | | | | | | | | | |

______________________________